КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 18 сентябрь г.Казань № 878

Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру буенча ниятләр турындагы килешүләргә, яңа инвестиция проектларының җыелма исемлегенә кертелгән яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру турындагы килешүләргә имза куюга вәкаләтләр бирү турында, шулай ук яңа инвестиция проектын тормышка ашыру буенча ниятләр турындагы килешүнең үрнәк формасын раслау хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа инвестиция проектларын (аларны тормышка ашыру максатларында Россия Федерациясе субъектының Россия Федерациясе алдында булган бюджет кредитлары буенча бурычларын каплау күләмен кимету нәтиҗәсендә Россия Федерациясе субъектының янга кала торган акчасы Россия Федерациясе субъекты тарафыннан инфраструктура объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга җибәрелергә тиешле) билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 19 октябрендәге 1704 номерлы карары белән расланган Яңа инвестиция проектларын (аларны тормышка ашыру максатларында Россия Федерациясе субъектының Россия Федерациясе алдында булган бюджет кредитлары буенча бурычларын каплау күләмен кимету нәтиҗәсендә Россия Федерациясе субъектының янга кала торган акчасы Россия Федерациясе субъекты тарафыннан инфраструктура объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга җибәрелергә тиешле) билгеләү кагыйдәләренең 6 пунктындагы дүртенче абзацы һәм 7[1] пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры М.Р.Шаһиәхмәтовка яңа инвестиция проектларын

тормышка ашыру буенча ниятләр турындагы килешүләргә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән кул куюга вәкаләт бирергә.

2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгын яңа инвестиция проектларының җыелма исемлегенә кертелгән яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру турындагы килешүләргә имза куюга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы итеп билгеләргә.

3. Яңа инвестиция проектын тормышка ашыру буенча ниятләр турындагы килешүнең үрнәк формасын (карарга теркәлә) расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 18 сентябрь, 878 нче
карары белән расланды

Үрнәк форма

Яңа инвестиция проектын тормышка ашыру буенча ниятләр турында
КИЛЕШҮ

______________________________ 20__ ел, «_____»
________(килешүне төзү урыны)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру буенча ниятләр турындагы килешүләргә, яңа инвестиция проектларының җыелма исемлегенә кертелгән яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру турындагы килешүләргә имза куюга вәкаләтләр бирү турында, шулай ук яңа инвестиция проектын тормышка ашыру ниятләре турындагы килешүнең үрнәк формасын раслау хакында» 2021 ел, 18 сентябрь, 878 нче карары нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры ________________________________________________ йөзендә, алга таба «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» дип атала, бер яктан, _________________________________________________________________________________
_________________________________________________ нигезендә эш итүче _________________________________________________________ йөзендә, алга таба «Инвестор» дип атала, икенче яктан, алга таба икесе бергә «Яклар» дип атала, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа инвестиция проектларын (аларны тормышка ашыру максатларында Россия Федерациясе субъектының Россия Федерациясе алдында булган бюджет кредитлары буенча бурычларын каплау күләмен киметү нәтиҗәсендә Россия Федерациясе субъектының янга кала торган акчасы Россия Федерациясе субъекты тарафыннан инфраструктура объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга җибәрелергә тиешле) билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 19 октябрендәге 1704 номерлы карары белән расланган Яңа инвестиция проектларын (аларны тормышка ашыру максатларында Россия Федерациясе субъектының Россия Федерациясе алдында булган бюджет кредитлары буенча бурычларын каплау күләмен киметү нәтиҗәсендә Россия Федерациясе субъектының янга кала торган акчасы Россия Федерациясе субъекты тарафыннан инфраструктура объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга җибәрелергә тиешле) билгеләү кагыйдәләренә таянып, түбәндәгеләр турында бу Килешүне (алга таба – Килешү) төзеделәр:

## 1. Килешү предметы

1.1. Бу Килешүнең предметы – Якларның Татарстан Республикасы территориясендә Яңа инвестиция проектларын (алга таба – яңа инвестиция проекты) билгеләү кагыйдәләрендә билгеләнгән яңа инвестиция проектларын сайлап алу критерийларына һәм эшчәнлек өлкәсенең берсенә туры килә торган __________
_______________________________________________________________________________
(инвестиция проекты исеме)
инвестиция проектын тормышка ашыру буенча ниятләре.

## 2. Якларның ниятләре

2.1. Инвестор, яңа инвестиция проекты Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан Яңа инвестиция проектларын билгеләү кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртиптә раслана торган яңа инвестиция проектларының җыелма исемлегенә кертелгән очракта, түбәндәгеләрне ниятли:

________ – __________ еллар чорында Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектын бу Килешүгә кушымтада күрсәтелгән параметрлар нигезендә тормышка ашырырга;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 20 сенә кадәр, җыелма исемлеккә кертелгән яңа инвестиция проектын тормышка ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына хисап кертергә;

әгәр яңа инвестиция проекты гамәлдәге юридик зат тарафыннан (бу максатлар өчен оештырылмаган аерым юридик зат тарафыннан) тормышка ашырылган очракта, Россия Федерациясе Салым кодексының 102 статьясы нигезендә түләнгән салымнарның гомуми күләме турындагы мәгълүматларны һәркем файдалана ала дип тануга ризалык бирергә.

2.2. Яңа инвестиция проекты Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан Яңа инвестиция проектларын билгеләү кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртиптә раслана торган яңа инвестиция проектларының җыелма исемлегенә кертелгән очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бюджет инвестицияләрен Яңа инвестиция проектларын билгеләү кагыйдәләренең 3 пунктында каралган формаларда яңа инвестиция проектын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларына юнәлдерергә ниятли.

## 3. Килешүнең гамәлдә булу срогы

3.1. Бу Килешү имза куелган датадан үз көченә керә һәм җыелма исемлеккә кертелгән яңа инвестиция проектын тормышка ашыру турында килешү төзегән вакытка кадәр гамәлдә була.

## 4. Конфиденциальлек

4.1. Яклар мәгълүматны ачуга карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә конфиденциаль мәгълүматның сакланышын тәэмин итәргә бурычлы.

4.2. Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалану мөмкинлеге чикләнә торган мәгълүмат конфиденциаль булып тора.

## 5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Бу Килешү Якларга бернинди дә финанс һәм (яки) мөлкәт йөкләмәләре бирми.

5.2. Бу Килешү рус телендә төзелгән һәм тигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә, һәр Як өчен берәр нөсхәдә имзаланган.

## 6. Якларның адреслары һәм Яклар вәкилләренең имзалары:

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | Инвестор |
| Адресы: 420060, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ирек мәйданы, 1 йорт | Адресы: |
| ______________________________ | ________________________________ |

Яңа инвестиция проектын тормышка ашыру буенча ниятләр турындагы 2021 елның ________ 878 номерлы килешүгә кушымта

## Яңа инвестиция проектын тормышка ашыру параметрлары

| Яңа инвестиция проектын тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Күрсәткеч исеме | Инвестиция проектын тормышка ашыру елы | | | | | | | | | | |
| | 1 нче | 2 нче | 3 нче | 4 нче | 5 нче | 6 нчы | 7 нче | 8 нче | 9 нчы | 10 нчы | Барлыгы |
| Яңа инвестиция проектына инвестицияләр, млн.сум | | | | | | | | | | | |
| Яңа инвестиция проекты кысаларында булдырылган эш урыннары саны | | | | | | | | | | | |
| Яңа инвестиция проектын тормышка ашырудан Россия Федерациясе бюджет системасының барлык дәрәҗәләрендәге бюджетларына салым керемнәре күләме*, млн.сум | | | | | | | | | | | |
| шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган яңа инвестиция проектларын тормышка ашырудан салым керемнәре керүне исәпләү методикасы нигезендә федераль бюджетка | | | | | | | | | | | |

| Яңа инвестиция проектын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектлары**: | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Инфраструктура объекты исеме | Объектның гомуми егәрлеге | | Яңа инвестиция проектын тормышка ашыру максатларында кулланыла торган егәрлек | |
| | мәгънәсе | үлчәү берәмлеге | мәгънәсе | үлчәү берәмлеге |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

*Салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә фактта капланган өстәлгән кыйммәткә салым күләмен тотып калып.

**Инфраструктура объектлары дигәндә яңа инвестиция проектын тормышка ашыру өчен кирәкле транспорт, инженерлык, энергетика һәм коммуналь инфраструктура объектлары, «Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» Федераль закон нигезендә булдырылган индустриаль (сәнәгать) паркларның, сәнәгать технопаркларының, махсус икътисадый зоналарның, алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләренең, инновацион фәнни-технологик үзәкләрнең инфраструктура объектлары аңлашыла.

---